Республика Татарстан
ВЕРХНЕСИМЕТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422068, Республика Татарстан, с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422068, Татарстан Республикасы, Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.09.2022 г.

КАРАР
№ 19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге чикләрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл башкарма комитетының 19.08.2016 ел, №28 карары белән расланган янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 21.12.1994 ел, №69-ФЗ Федераль закон һәм «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» 14.07.2022 ел, №276-ФЗ Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Югары Симет авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турындагы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Югары Симет авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында» 2016 елның 19 августындагы 28 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 нче пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чарасы булып янгын сүндерүне оештыру буенча чаралар комплексының бер өлеше булган янгыннарны булдырмау, кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннардан коткару буенча билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән нормаларны һәм кагыйдәләрне тормышка ашыру тора.

Авыл җирлекләре чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- ирекле янгын куркынычсызлыгын оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук гражданнарның башка формаларда янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларда катнашуы;

-янгын сүндерү максатларында елның теләсә кайсы вакытында тышкы су белән тәэмин итү чыганакларыннан, авыл торак пунктларында һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә су алу өчен шартлар тудыру;

- гомуми файдалану территорияләрен янгыннарны сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь белән тәэмин итү;

-янгын турында халыкка һәм дәүләт янгынга каршы хезмәте бүлекчәләренә хәбәр итү буенча чаралар оештыру һәм кабул итү;

-янгынны локальләштерү, кешеләрне һәм мөлкәтне янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләре килгәнче коткару буенча чаралар күрү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын җирлекләр, муниципаль һәм шәһәр округлары территорияләрен үстерү планнарына, схемаларына һәм программаларына кертү;

- Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында, шул исәптән халык җыелышларын оештыру һәм уздыру юлы белән хәбәр итүдә ярдәм күрсәтү;

- янгын куркынычы арткан очракта, махсус янгынга каршы режим урнаштыру.»

1.2. 6.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итүгә керә:

1) су челтәрендә урнаштырылган янгын гидрантлары белән үзәкләштерелгән һәм (яки) үзәкләштерелмәгән су белән тәэмин итү системалары (янгынга каршы тышкы сууткәргеч);

2) Россия Федерациясе законнары нигезендә янгын сүндерү максатларында кулланыла торган су объектлары;

3) янгын сусаклагычлары.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Югары Симет авыл
җирлеге башлыгы И.Р.Әхмәдуллин